Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Күн авыл җирлеге Советы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Күн авыл җирлеге башлыгы
**КАРАРЫ**

7 февраль, 2023 ел № 1

Җир кишәрлекләреннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча иҗтимагый фикер алышулар билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Күн авыл җирлегендә 2017 елның 21 августындагы 63 номерлы карары белән расланган иҗтимагый фикер алышуларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә, кергән гаризалар нигезендә, карар бирәм:

1. Җир кишәрлекләреннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча иҗтимагый фикер алышулар уздыруны билгеләргә:

- ж/к кадастр номеры 16:33:040106:392, мәйданы 620 кв.м., адресы: ТР, Питрәч районы, Күн авыл җирлеге, Күн авылы, Мәктәп урамы - «13.2 Бакчачылык алып бару» индивидуаль торак зонасында (Ж1),
- ж/к кадастр номеры 16:33:040106:393, мәйданы 277 кв.м., адресы: ТР, Питрәч районы, Күн авыл җирлеге, Күн авылы, - «13.2 Бакчачылык алып бару» индивидуаль торак зонасында (Ж1),

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

2.1. Иҗтимагый фикер алышулар уздыруны оештыручы - Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Күн авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясе (алга таба - Комиссия);

2.2. Иҗтимагый фикер алышулар үткәрү датасы, вакыты һәм урыны - 2023 елның 15 февралендә, 10.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты бинасында: Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Питрәч авылы, Питрәч ав., Совет ур., 18 нче йорт адрес буенча;

2.3. адресы буенча, авторның фамилиясен, исемен, атасының исемен, туган елын, яшәү урыны адресын күрсәтеп, язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр тапшырыла ала торган адрес - Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Күн авыл җирлеге башкарма комитеты бинасы: Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Күн авыл җирлеге, Күн ав., Мәктәп ур., 1а й. адресы буенча (дүшәмбе-җомга 8-00 дән 12-00 гә кадәр һәм 13-00 сәгатьтән 16-00 сәгатькә кадәр төшке аш тәнәфесе 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр).

3. Комиссиягә:

3.1. Иҗтимагый фикер алышулар уздыру йомгаклары буенча иҗтимагый фикер алышулар беркетмәсе, иҗтимагый фикер алышулар нәтиҗәләре буенча бәяләмә әзерләргә;

3.2. Иҗтимагый фикер алышулар нәтиҗәләрен Питрәч муниципаль районы Интернет челтәрендәге рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) урнаштырырга;

3.3. «Вперед» («Алга») газетасында иҗтимагый фикер алышулар үткәрү турында хәбәрне бастырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Питрәч муниципаль районы
Күн авыл җирлеге башлыгы Р.Г. Баһауов